# Актанышлар көрәшне үз итте

Район җитәкчелеге киләсе елда да көрәш буенча республика һәм илкүләм ярышларны Актанышта үткәрергә тәкъдим итте.

Энҗе ГАБДУЛЛИНА

«Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган Муса Җәлил истәлегенә багышланган көрәш ярышлары быел 13-15 февраль көннәрендә Актанышта узды. Бу – район хакимияте башлыгы Энгель Фәттаховның тәкъдиме булды. Быелгы ярышлар беренче тапкыр ике турнирны берләштерде. 15-18 февральдә Муса Җәлил истәлегенә көрәш буенча Бөтенроссия турниры да үткәрелде.

Актанышның «Батыр» универсаль-спорт комплексында узган ярышта Татарстан районнарыннан килгән 335 көрәшче бил алышты. Бөтенроссия ярышына Башкортстан, Марий Эл, Чувашия, Удмуртия республикалары, Ульяновск, Самара, Киров, Свердловск, Түмән өлкәләре – барлыгы 15 төбәктән 55 көрәшче җыелды.


Ярышларны ачу тантанасында ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, Татарстанның Милли көрәш федерациясе президиумы рәисе Марат Әхмәтов, ТР спорт министрының беренче урынбасары Хәлил Шәйхетдинов, «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәррире Миңназыйм Сәфәров катнашты. Алар үткән елга нәтиҗәләр ясап, иң яхшы көрәшчеләрне, тренерларны, командаларны һәм журналистларны бүләкләде.

ҖИҢҮЧЕЛӘР:

| | |
|---|---|
| **Тимур Милютин** | (60 кг, Әлмәт) |
| **Искәндәр Мортазин** | (65 кг, Актаныш) |
| **Рөстәм Сәлахов** | (70 кг, Яңа Чишмә) |
| **Артур Зөлкарнәев** | (75 кг, Теләче) |
| **Ренас Кәлимуллин** | (80 кг, Теләче) |
| **Раил Сәләхетдинов** | (85 кг, Кукмара) |
| **Илнар Галимов** | (90 кг, Актаныш) |
| **Айнур Сыртлан** | (100 кг, Чистай) |
| **Муса Галимов** | (130 кг, Теләче) |
| **Марат Мөхәммәтҗанов** | (130 кг югары, Түбән Кама) |

Ярышларның нәтиҗәләре буенча Татарстан командалары арасында Теләче районы – беренче, Актаныш районы – икенче, Әлмәт районы өченче урынга лаек булды.

Турнир финалыннан соң Энгель Фәттахов киләсе елда да көрәшчеләрне бил алышырга Актанышка чакырды. Үз Актаныш командасының быелгы ярышта икенче урынны яулавын соңгы 20 елда иң зур җиңү дип атады. «Көрәшчеләребезгә зур рәхмәт, җиңүчеләрне котлыйм, киләчәктә тагын да зуррак җиңүләр яуларга язсын», – диган теләкләрен җиткерде **Энгель Фәттахов**.



Турнирның абсолют батыры ачыкланмады. Һәр үлчәү авырлыгындагы җиңүчеләргә абсолют батыр исеме өчен көрәшү мөмкинлеге бирелде. Тик көрәшергә теләк белдерүче генә табылмады. Көрәш федерациясенең башкарма директоры Равил Хәйруллин киләчәктә абсолют батыр дигән исемне кире кайтарырга теләвен әйтте.

– Бу турнирда абсолют батырны ачыкламакчы идек. Тик 130 килограммнан югары үлчәүдә җиңгән батыр бик көчле көрәшче. Башкалар: «Аның белән көрәшеп тормасак та була», – диделәр. Район башлыгы Энгель Фәттахов абсолют батырга дигән такъяне җиңүче командага тапшырырга булды, – диде **Равил Хәйруллин**.

Шул рәвешле, тәкә Теләче районы командасына бүләк ителде.

Бөтенроссия ярышында исә тугыз үлчәү авырлыгының сигезендә Татарстан командасы егетләре чемпион калды. Турнирның дәрәҗәсе зур: һәр үлчәү авырлыгында җиңүчеләр Россиянең спорт остасы дигән мактаулы исемгә лаек булачак. Төбәкләр арасында Татарстан – беренче, Башкортстан – икенче, Марий Эл өченче урынны яулады.

НАСКО

Специальное предложение

«ДОРОГИМ И ЛЮБИМЫМ»*

При страховании имущества специальные условия по страхованию ответственности


Подробности на сайте www.nasko.ru и по телефону 8-800-500-16-16



РЕКЛАМА

КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

## КУЛЛАНУ КРЕДИТЫ: хокукка ташлама ясарга мөмкинме?



**«Микрофинанс оешмасы куллану кредиты килешүе буенча башка затларга таләпләр хокукларына ташлама ясый аламы? Бу законга ни дәрәҗәдә туры килә? Әгәр законга каршы килми икән, микрофинанс оешмасы бу алымны кемнәргә карата куллана ала?»**

В.Чугреева

**Укучыбызның соравына Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең үсеш һәм координация бүлеге белгечләре җавап бирде:**

– Әйе, бу мөмкин хәл. Ул 2018 елның 27 декабрендә кабул ителгән «Куллануча кредиты (займ) турында»гы Федераль закон һәм «Микрофинанс эшчәнлеге һәм микрофинанс оешмалары турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»гы Федераль канунда каралган. Закон нигезендә, кредитор куллану кредиты килешүе буенча таләпләр хокукларына ташламаны түбәндәге очракларда ясарга хокуклы:

1. Куллану займнары тәкъдим итү буенча һөнәри эшчәнлек алып баручы юридик затка;
2. Эшчәнлекнең төп төре сыйфатында физик затларның үз вакытында түләнмәгән бурычын кайтару буенча эшчәнлек алып баручы юридик затка;
3. Махсуслашкан финанс җәмгыятенә;
4. Бурычка алучыда куллану кредиты килешүе буенча үз вакытында түләнмәгән бурыч хасил булганнан соң, кредитор тарафыннан алынган заемчының язмача килешүендә күрсәтелгән физик затка.

*Шул ук вакытта, бурычка алучының яңа кредиторга карата аңа федераль закон нигезендә беренчел кредитор сыйфатында бирелгән барлык хокуклары да саклана.*